КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 10 апрель г.Казань № 272

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау чаралары турында» 2020 ел, 19 март, 208 нче карарына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасында санитар-эпидемиологик хәлне һәм яңа коронавирус йогышлы авыруы таралу үзенчәлекләрен исәпкә алып Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау чаралары турында» 2020 ел, 19 март, 208 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 25 март, 218 нче, 2020 ел, 27 март, 223 нче, 2020 ел, 30 март, 234 нче, 2020 ел, 31 март, 240 нчы, 2020 ел, 03 апрель, 252 нче, 2020 ел, 06 апрель, 260 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), аны яңа редакциядә бәян итеп (карарга теркәлгән), үзгәреш кертергә:

2. Бу карар басылып чыккан көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 19 март, 208 нче
карары
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 10 апрель, 272 нче
карары редакциясендә)

Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау чаралары турында

Яңа коронавирус йогышы авыруы таралу куркынычы белән бәйле рәвештә һәм «Халыкның санитар-эпидемиология иминлеге турында» 1999 елның 30 мартындагы 52-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Президентының «Яңа коронавирус йогышлы авыруы (COVID-19) таралуга бәйле рәвештә Россия Федерациясе территориясендә халыкның санитар-эпидемиологик иминлеген тәэмин итү чаралары турында» 2020 елның 2 апрелендәге 239 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасы органнары һәм көчләре өчен югары әзерлек режимын кертү турында» 2020 елның 19 мартындагы 129 номерлы боерыгы нигезендә, шулай ук Россия Федерациясе территориясендә яңа коронавирус йогышлы авыруын алып керту һәм таратуны кисәтү буенча оператив штаб карарларын, Россия Федерациясе Баш дәүләт санитар табибы карарларын гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Халыкның санитар-эпидемиологик иминлеген тәэмин итүгә, шул исәптән Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасы идарәсе органнары һәм көчләре өчен югары әзерлек режимы шартларында, чикләү һәм башка чаралар комплексын гамәлгә ашыру Татарстан Республикасының бөтен территориясендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

2. Гражданнарның турыдан-туры катнашында ял, күңел ачу, тамаша, мәдәни, физкультура, спорт, күргәзмә, агарту, реклама һәм башка шундый чаралар үткәрү, шулай ук тиешле хезмәтләр күрсәтү, шул исәптән мәдәният һәм ял паркларында, сәүдә һәм сәүдә-күңел ачу үзәкләрендә (комплексларда), аттракционнарда һәм гражданнар күпләп йөри торган башка урыннарда да рөхсәт ителми дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы территориясендә спорт үзәкләре, йөзү бассейннары, фитнес-үзәкләр, кинотеатрлар (кинозаллары), төнге клублар (дискотекалар), балалар уен бүлмәләре, балалар күңел ачу үзәкләре һәм башка күңел ачу оешмалары эшчәнлеген туктатып торырга.

4. 2020 елның 28 мартыннан башлап санитар-эпидемиологик хәлне яхшырту өчен эшне туктатып торырга:

а) сәүдә, сәүдә-күңел ачу үзәкләрендә (комплексларында), ваклап сату базарларында, аларда булган түбәндәгеләрдән тыш:

даруханәләр һәм даруханә пунктлары;

азык-төлек товарлары сатучы ваклап сату объектлары;

урамнан аерым керү урыны булган мобиль элемтә хезмәтләре күрсәтү өчен килешүләр төзү гамәлгә ашырыла торган объектлар;

б) башка ваклап сату объектларында, түбәндәгеләрдән тыш:

даруханәләр, даруханә пунктлары;

азык-төлек товарларын сатучы объектлар;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 27 мартындагы 762-р номерлы боерыгы белән расланган беренче чиратта кирәкле азык-төлек булмаган товарлар исемлегенә кертелгән товарларны, үсемлек орлыклары, суган, бүлбеләр һәм тамырлар, үсемлекләр һәм үсентеләр, үсемлекләр үсентеләре, ашламалар, туфрак һәм бакчачылык алып бару өчен товарлар сатучы, шулай ук мобиль элемтә хезмәте күрсәтүгә шартнамәләр төзү гамәлгә ашырыла торган гомуми мәйданы 100 кв.метрдан кимрәк булган объектлар;

в) җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтү объектлары, гражданнарның мондый объектларның биналарына кермичә генә алып чыгудае, шулай ук заказлар китерүдән тыш;

г) матурлык салоннары, СПА-салоннар, косметика, массаж салоннары, солярийлар, мунча, саун һәм мондый хезмәтләр күрсәтелә торган башка объектлар.

Чикләүләр товарларны дистанцион ысул белән сатуга, товарларны китереп бирүгә, ирекле сату Россия Федерациясе законнары белән тыелган яки чикләнгән товарлардан тыш, шулай ук оешмалар биналарында әлеге оешмалар хезмәткәрләренә җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтүгә таралмый.

5. Россия Федерациясе Президентының «Яңа коронавирус йогышлы авыруы (COVID-19) таралуга бәйле рәвештә Россия Федерациясе территориясендә халыкның санитар-эпидемиологик иминлеген тәэмин итү чаралары турында» 2020 елның 2 апрелендәге 239 номерлы Указының 5 пункты нигезендә Россия Федерациясе Хөкүмәте белән килештерелгән Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан система барлыкка китерүче, шулай ук фәнни һәм белем бирү оешмаларының эшчәнлеген санитар-эпидемиологик хәл яхшырганчы туктатып торырга (чикләргә).

6. 2020 елның 28 мартыннан санитар-эпидемиологик хәл яхшырганчыга кадәр шифаханә-курорт оешмаларында (санаторийларда), ел әйләнәсе эшли торган шифаханә-савыктыру балалар лагерьларында урыннар броньлау, гражданнарны кабул итү һәм урнаштыру эшләрен туктатырга, хезмәт командировкаларында яки хезмәт сәфәрләрендә булган затлардан тыш.

Әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән оешмаларга аларда

урнаштырылган затларга карата:

үзизоляцияләү һәм кирәкле санитар-эпидемиологик чаралар үткәрү өчен, аларның яшәү вакыты тәмамланганчы, аны озайту мөмкинлегеннән башка, шартлар тәэмин итәргә;

Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт аңлатмалары нигезендә әлеге затларны тукландыруны турыдан-туры алар яшәгән биналарда оештырырга.

7. 2020 елның 30 мартыннан башлап санитар-эпидемиологик хәл яхшырганчыга кадәр гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алуны, тууны, үлемне дәүләт теркәвенә алудан, шулай ук гаилә законнары нигезендә аерым шартлар булганда никах теркәүне дәүләт теркәвенә алудан гайре, туктатып торырга.

8. Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә билгеләргә:

2020 елның 30 мартыннан 2020 елның 14 апреленә кадәр дәүләт, муниципаль һәм башка хезмәтләр күрсәтү турында гаризалар һәм документлар кабул итү туктатыла;

2020 елның 13 апреленнән башлап санитар-эпидемиологик хәл яхшырганчыга кадәр гариза бирүчеләрне бары тик дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы, дәүләт хакимияте органнарының һәм җирле үзидарә органнарының рәсми сайтлары аша электрон рәвештә хезмәт күрсәтүгә гаризалар (соратулар) бирү каралмаган хезмәтләргә карата гына кабул итү гамәлгә ашырыла, бары тик билгеле бер датага һәм вакытка алдан язылу буенча гына.

9. 2020 елның 6 апреленнән башлап санитар-эпидемиологик хәл яхшырганчыга кадәр эшчәнлекләрен туктатып торырга:

дәүләт тернәкләндерү үзәкләренең;

сәламәтлекләре мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләренең;

халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәкләренең социаль-тернәкләндерү бүлекләренең;

Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтүләрне тәэмин итүчеләр реестрына кертелгән, ләкин дәүләт йөкләмәсен (заказын) үтәүдә катнашмый торган инвалидларга, 65 яшьтән өлкәнрәк гражданнарга, инвалид балаларга реабилитация хезмәтләре күрсәтүче дәүләтнеке булмаган социаль хезмәтләр күрсәтүчеләрнең.

10. 2020 елның 30 мартыннан башлап санитар-эпидемиологик хәл яхшырганчыга кадәр йөкләргә:

а) 65 яшьтән өлкәнрәк гражданнар, шулай ук әлеге карарның 1 нче кушымтасында күрсәтелгән авырулары булган затлар, гомеренә һәм сәламәтлегенә турыдан-туры янау очракларыннан тыш, яшәү (тору) урыннарыннан китмәскә. Әлеге чикләү эш урынында булу эш бирүченең эшләвен тәэмин итү өчен критик әһәмияткә ия булган оешма һәм хакимият органнары җитәкчеләренә һәм хезмәткәрләренә кагылмый, эш бирүченең Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән форма буенча документы (белешмәсе) булганда;

б) башка гражданнарны яшәү (тору) урыннарыннан, ашыгыч (кичектергесез) медицина ярдәме сорап мөрәҗәгать итү очракларыннан һәм гомеренә һәм сәламәтлегенә турыдан-туры янауның башка очракларыннан, шулай ук әлеге карар

нигезендә аларны сату чикләнмәгән товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуның якындагы урынына бару, яшәү (тору) урыныннан 100 метрдан артмаган арада йорт хайваннарын йөртү, калдыкларны якындагы калдыклар җыю урынына кадәр чыгару очракларыннан тыш. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән форма буенча эш бирүче документы (белешмәсе) булганда, әгәр эшчәнлекне гамәлгә ашыру законнар нигезендә туктатылмаган булса, Татарстан Республикасы территориясе буенча хәрәкәт итү рөхсәт ителә;

в) гражданнарны башка гражданнардан 1,5 метрдан да ким булмаган дистанцияне (социаль дистанция) сакларга, шкл исәптән җәмәгать урыннарында һәм җәмәгать транспортында, җиңел таксида пассажирлар һәм багаж ташудан тыш;

г) эшчәнлекләре гражданнарның бергә булуы белән бәйле булган хакимият органнарының, оешмаларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең, шулай ук башка затларның, гражданнарның (шул исәптән хезмәткәрләр) социаль дистанцияне үтәвен тәэмин итәргә, шул исәптән махсус тамга төшерү һәм биналарга, төзелмәләргә, корылмаларга (алардагы бүлмәләргә), тиешле территориягә (янәшә территорияне дә кертеп) махсус билгеләмә төшерү һәм керү һәм булуның махсус рөхсәт режимын билгеләү юлы белән;

д) чит ил дәүләтләре территориясеннән кайткан гражданнар:

беренче респиратор симптомнар барлыкка килгәндә кичекмәстән, медицина оешмаларына кермичә, өйдә медицина ярдәме сорап мөрәҗәгать итәргә;

өйдә изоляция режимын үтәргә;

е) чит ил дәүләтләре территориясеннән кайткан гражданнарның изоляциясен тәэмин итү чорында алар белән бергә яшәүче затларга 14 календарь көнгә өйдә үзизоляцияләүне тәэмин итәргә.

Әлеге пунктның беренче – өченче абзацларда билгеләнгән чикләүләр медицина ярдәме күрсәтү очракларына, дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары, хокук саклау органнары, гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр органнары һәм аларга буйсынган оешмалар, кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек органнары, гражданнарның тормышын, сәламәтлеген һәм башка хокукларын һәм ирекләрен турыдан-туры яклау өлешендә башка органнарга, шул исәптән җинаятьчелеккә каршы тору, җәмәгать тәртибен саклауга юнәлдерелгән гамәлләр өлешендә, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә бирелгән махсус рөхсәтләре булган гражданнарга, тиешле органның вазыйфаи заты чакыртуы буенча хокук саклау органына яки прокуратурага баручы һәм кире кайтучы гражданнарга, аларның чакыруны раслаучы билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән документлары булганда, кагылмый.

11. Тыярга:

2020 елның 30 мартыннан башлап санитар-эпидемиологик хәл яхшырганчыга кадәр паркларга, урман паркларына керүне һәм аларда булуны. Әлеге тыю әлеге объектларга хезмәт күрсәтүче оешмалар хезмәткәрләренә кагылмый;

2020 елның 11 апреленнән башлап санитар-эпидемиологик хәл яхшырганчыга кадәр гражданнарга зиратларга керүне, җирләү (күмү) буенча хезмәтләр күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итү һәм җирләүдә (күмүдә) катнашу очракларыннан тыш.

12. Оешмаларга һәм шәхси эшмәкәрләргә:

тарту өчен кальяннар бирү, кальяннар куллану буенча хезмәтләр күрсәтүгә юл куймаска;

хезмәткәрләргә өйдә үзизоляцияләү режимын үтәүне тәэмин итүдә ярдәм күрсәтергә;

Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе соратуы килеп ирешкән очракта, коронавирус йогышлы авыруы белән авыручының хезмәт функцияләрен үтәү белән бәйле рәвештә барлык контактлары турында мәгълүматны кичекмәстән тапшырырга, авырган кеше булган эш урыннарын һәм бүлмәләрне дезинфекцияләүне тәэмин итәргә;

гамәлдәге санитар кагыйдәләрне һәм гигиеник нормативларны, шулай ук федераль дәүләт санитар-эпидемиология күзәтчелеген гамәлгә ашыручы орган (вазыйфаи зат) күрсәтмәләрен һәм таләпләрен тайпылышсыз үтәүне тәэмин итәргә.

13. Россия Федерациясе Президентының «Яңа коронавирус йогышлы авыруы (COVID-19) таралуга бәйле рәвештә Россия Федерациясе территориясендә халыкның санитар-эпидемиологик иминлеген тәэмин итү чаралары турында» 2020 елның 2 апрелендәге 239 номерлы Указының 4 пунктындагы «ж» пунктчасы нигезендә аның Татарстан Республикасында гамәлдә булуы әлеге карарның 2 нче кушымтасында күрсәтелгән оешмаларга кагылмый дип билгеләргә.

14. Эшчәнлеге туктатылмаган (чикләнмәгән) оешмаларга Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә эш белән тәэмин итү үзәкләренә булган вакансияләр турында аларның барлыкка килүе буенча белешмәләр тапшырырга.

15. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына, оешмалар һәм шәхси эшмәкәрләргә:

хезмәткәрләр арасында коронавирус йогышлы авыруын профилактикалау буенча кирәкле чаралар күрергә;

ялга яисә шәхси хәлләр белән Россия Федерациясеннән читкә чыгып киткән хезмәткәрләр чит илләрдән кайткан очракта, аларның эшләвенә юл куймаска һәм аларны Россия Федерациясе территориясенә килеп төшкәннән соң 14 календарь көнгә үзизоляцияләү зарурилыгы турында кисәтергә;

корреспонденцияне кабул итү һәм җибәрүне бары тик ведомствоара электрон документ әйләнеше системасы, электрон һәм почта элемтәсе аша гына тормышка ашырырга.

16. 2020 елның 1 апреленнән башлап санитар-эпидемиологик хәл яхшырганчыга кадәр түбәндәгеләрне билгеләргә:

муниципальара пассажирлар һәм багаж ташу гамәлгә ашырылмый, Казан шәһәренә һәм кирегә, шулай ук Чаллы шәһәренә һәм кире кайтучы шәһәр яны маршрутлары буенча даими пассажирлар һәм багаж ташудан тыш;

Татарстан Республикасыннан йөкләр җибәрү белән бәйле ташулар, шулай ук Татарстан Республикасы чикләрендә йөкләр ташулар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән форма буенча җибәрүче оешма биргән белешмә булганда гамәлгә ашырыла;

җиңел таксида икедән артык пассажирны (балигъ булмаган затларны исәпкә алмыйча) машина йөртүче һәм барлык пассажирларны да сулыш органнарын шәхси саклау чараларыннан (битлек, ресираторлар) файдаланмыйча йөртү рөхсәт ителми.

17. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына:

амбулатор һәм стационар медицина ярдәме күрсәтүне гамәлгә ашыручы, ашыгыч медицина ярдәме күрсәтүче медицина оешмаларының көчле вируслы йогышлы авырулар симптомнары, шул исәптән хастаханәдән тыш пневмония белән авыручыларны кабул итүгә һәм аларга кичектергесез медицина ярдәме күрсәтүгә, коронавирус йогышлы авыруына тикшеренүләр үткәрү өчен һәм күрсәткечләр буенча авыручылардан биологик материал алуга әзерлеген тәэмин итәргә;

медицина ярдәме күрсәтүче медицина оешмаларында вируска каршы препаратлар, шул исәптән коронавирус йогышлы авыруын дәвалау өчен тәкъдим ителгән препаратларның, дезинфекцияләү чаралары һәм индивидуаль саклану чараларының кимеми торган запасларын булдыруны тәэмин итәргә;

коронавирус йогышлы авыруы буенча имин булмаган территорияләрдән кайткан барлык гражданнарны 14 календарь көн эчендә көн саен медицина күзәтүендә тотуны оештырырга;

респиратор авыруларның беренче симптомнары барлыкка килгәндә медицина ярдәме күрсәтү өчен үз вакытында мөрәҗәгать итү кирәклегенә аерым игътибар биреп, халык белән гриппны, көчле вируслы йогышлы авыруларны, коронавирус йогышлы авыруын, хастаханәдән тыш пневмонияләрне профилактикалау турында аңлату эшләрен үткәрүне тәэмин итәргә.

18. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына, Татарстан Республикасының югары уку йортлары ректорлары советына Татарстан Республикасы мәгариф оешмаларында коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау буенча нәтиҗәле чаралар күрергә.

19. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгына Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнары, «Бердәм Россия» Бөтенроссия сәяси партиясенең Татарстан төбәк бүлеге, «Гомумроссия халык фронты» төбәк бүлеге, Татарстан Республикасы Һөнәр берлекләре федерациясе белән берлектә тәэмин итәргә:

гражданнарның аерым категорияләренә дарулар, азык-төлек һәм беренче чиратта кирәкле товарлар китерү буенча волонтерлар эшен;

гражданнарның аерым категорияләренә дарулар, азык-төлек һәм беренче чиратта кирәкле товарлар китерү мәсьәләләре буенча «кайнар линия» телефоннары эшен;

волонтерларны шәхси саклану чаралары (саклагыч битлекләр, антисептикалар, перчаткалар) белән.

20. Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан расланган яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау максатларында кертелгән тыюлар һәм чикләүләр гамәлдә булган чорда Татарстан Республикасында

йөрүгә махсус рөхсәтләр бирү тәртибе таләпләрен үтәү мәсьәләләре буенча гражданнарга тәүлек буе консультация ярдәме күрсәтүне тәэмин итәргә.

21. Тәкъдим итәргә:

Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсенә Татарстан Республикасы территориясендә коронавирус йогышлы авыруының Татарстан Республикасына керүен һәм таралуын булдырмау буенча эпидемиягә каршы чаралар комплексын үткәрүне тәэмин итүне;

Россия Федерациясе Федераль иминлек хезмәтенең Татарстан Республика-сы буенча идарәсенә, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына коронавирус йогышлы авыруының Татарстан Республикасына керүен һәм таралуын булдырмау буенча чаралар күрүдә Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсенә, Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарына һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына булышлык күрсәтүне;

Россия Федерациясе Милли гвардиясе гаскәрләре федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә, шәхси сак оешмаларына әлеге карарның 4 пунктындагы «а» пунктчасы нигезендә эшләре туктатылган объектларның сакланышын тәэмин итүгә юнәлдерелгән чаралар күрергә.

22. «Татарстанның медицина техникасы һәм фармациясе» дәүләт унитар предприятиесенә дарухanә челтәрендә вируска каршы препаратлар, шул исәптән коронавирус йогышлы авыруын дәвалау өчен тәкъдим ителгән препаратларның, дезинфекцияләү чаралары һәм индивидуаль саклану чараларының кимеми торган запасларын булдыруны тәэмин итүне оештырырга.

23. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына Татарстан Республикасында коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау буенча үткәрелә торган чараларны массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртуны оештырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 19 март, 208 нче
Карарына 1 нче кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 10 апрель, 272 нче
карары редакциясендә)

Үзизоляцияләү режимын үтәүне таләп итә торган авырулар
исемлеге

1. Эндокрин системасы авыруы – E10 диагнозы буенча 10 (МКБ-10) Авыруларны халыкара классификацияләү нигезендә классификацияләнә торган инсулинга бәйле шикәр диабеты.

2. Сулыш органнары авырулары түбәндәгеләр арасыннан:

2.1. J44 диагнозы буенча МКБ-10 нигезендә классификацияләнә торган башка хроник обструктив үпкә авыруы.

2.2. J45 диагнозы буенча МКБ-10 нигезендә классификацияләнә торган астма.

2.3. J47 диагнозы буенча МКБ-10 нигезендә классификацияләнә торган бронхоэктатик авыру.

3. Кан әйләнеше системасы авыруы – үпкә йөрәге һәм үпкә кан әйләнеше бозылулары, I27.2, I27.8, I27.9 диагнозлары буенча МКБ-10 нигезендә классификацияләнә.

4. Z94 диагнозы буенча МКБ-10 нигезендә классификацияләнгән трансплантацияләнгән органнар һәм тукымалар булу.

5. Сидек-җенес системасы авыруы* – бөерләрнең 3 – 5 стадиядәге хроник авыруы, 18.0, 18.3-18.5 номерлы диагнозлар буенча МКБ-10 нигезендә классификацияләнә.

6. Түбәндәгеләрдән шешләр**:

6.1. Теләсә кайсы локализациядәге яман шешләр*, шул исәптән C00 – C80, C97 диагнозлары буенча МКБ-10 нигезендә классификацияләнә торган мөстәкыйль күп санлы локализацияләрдә.

6.2. Кискен лейкозлар, яманлыгы югары булган лимфомнар, башка лимфопролифератив авыруларның рецидивлары һәм резистент рәвешләре, хроник акселерация һәм бласт кризисы фазаларында хроник миелолейкоз, беренчел хроник лейкозлар һәм лимфомнар* C81 – C96, D46 диагнозлары буенча МКБ-10 нигезендә классификацияләнә торган.

---

*Үзизоляцияләү режимында төп авыру уңаеннан медицина оешмасына бару рөхсәт ителә.

**Үзизоляцияләү өченче клиник төркемгә (онкологиядә) кертелгән пациентларга кагылмый.

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 19 март, 208 нче
Карарына 2 нче кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 10 апрель, 272 нче
карары редакциясендә)

Россия Федерациясе Президентының «Яңа коронавирус йогышлы авыруы (COVID-19) таралуга бәйле рәвештә Россия Федерациясе территориясендә халыкның санитар-эпидемиологик иминлеген тәэмин итү чаралары турында» 2020 елның 2 апрелендәге 239 номерлы Указы гамәле Татарстан Республикасында кагылмаган оешмалар исемлеге

Туктаусыз эшләп килүче оешмалар өчен товарлар белән тәэмин итү, эшләр башкару һәм хезмәтләр күрсәтү эшчәнлеген алып баручы оешмалар.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау чаралары турында» 2020 ел, 19 март, 208 нче карарының 5 пункты нигезендә эшчәнлекләре туктатылган (чикләнгән) система барлыкка китерүче оешмалардан тыш, товарлар белән тәэмин итү, эшләр башкару һәм хезмәтләр күрсәтү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалар.

Нефть, газ, химия комплексы оешмалары өчен товарлар белән тәэмин итү, эшләр башкару һәм хезмәтләр күрсәтү эшчәнлеген алып баручы оешмалар.

Дәүләт оборона заказын үтәүне тәэмин итүче оешмалар.

Кичектергесез нотариаль гамәлләр кылучы нотариуслар һәм аларның эшчәнлеген тәэмин итүче затлар.

Адвокатлар һәм аларның эшчәнлеген тәэмин итүче затлар.

Төзелеш оешмалары.

Төзелеш материалларын җитештерүче оешмалар.

___